# “Әниләр ялгыз булырга тиеш түгел!”
# Әмирхан Еники
# “Әйтелмәгән васыять”

7- сыйныфлар өчен әдәбият дәресләренә кулланма.

**Кулланма авторы: М.Х.Гайнуллин ис. Кызылтау урта гомуми белем бирү мәктәбенең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Шәрәфуллина Гөлинә Мәнср кызы**.

# Кабатлап искә төшерү (Фатих Кәрим иҗаты)

Саратский яшел гармун,

Көмеш кыңгыраулары,

Бу көмеш кыңгырауларның

Кичке яңгыраулары

Әллә нишләтә күңелне,

Үксеп елыйсы килә...

Елау егет эшемени?!-

Эх, бер җырлыйсы килә!..

# Жанрлар:

- Эпик төр.
- Лирика.
- Лиро-эпик төр.
- Драма.

# Эпик төр жанрлары

- \- новелла
- \- хикәя
- \- повесть
- \- роман

- **Хикәя** - кечкенә күләмле, сурәтләү материалы итеп тормыш чынбарлыгын алган, чикле сандагы геройлар турында язылган, мөһим ягын җыйнак сурәтләгән чәчмә әсәр.

# ӘМИРХАН ЕНИКИ

- Ә татар әдәбиятында хикәяләү остасы ул- Әмирхан Еники. Остаз үзе әйткәнчә: "Сәнгатьчә эшләнгән һәрбер яхшы хикәянең үз моңы, үз көе, ничектер үзенә генә хас эчке сулышы, җаны була. Мин моны язучының хикәягә салган настроениесе дияр идем. Бу моң бөтен хикәя өчен бердәм була."



# БИОГРАФИК МӘГЪЛҮМАТ

| Вакыты | Тормыш юлы |
| --- | --- |
| 2.03.1909 | Башкортстанның Благовар районы Яңа Каргалы авылында Әмирхан Еники туа. |
| 1911 | Гаиләләре Дәүләкән авылына күчә |
| 1925 | Сәнгать мәктәбендә уку теләге белән Еники Казанга килә |
| 1927-1933 | Донбасста укыта |
| 1934-1941 | Казанда кинофикация трестында инструктор. |
| 1941-1945 | Ватан сугышында катнаша |
| 1953 елдан | Язучылык хезмәтенә күчә |
| 16.02.2000 | Казанда вафат була |

- *Без бүген Әдипнең “Әйтелмәгән васыять” әсәрен укырбыз.*
- *Әсәрдәге вакыйгаларның **төенләнешен** белдек.*

  *Кәфенлек онытылып калды.*

- *Киләсе дәресләрдә сез **кульминацион** вакыйганы һәм **чишелешләрне** табарсыз.*

- *Төп герой – Акъәби,*
- *Ярдәмче геройлар – Гарифә, Гөлбикә, кияү, Миңнегали карт.*
- *Эпизод геройлары – авылдашлар,*
- *Табигый образлар- дала*
- *җыелма образлар- туган авыл,*
- *Ясалма образ- учак.*

# Нәтиҗә.

- *Акъәби – үз гомерен балаларына багышлаган ялгыз ана. Аның борчу-мәшәкатьләрен, уйларын, шатлыкларын бүлешергә дә кешесе юк.Ә бит алай булырга тиеш түгел. Әни кеше кадер хөрмәттә, җылы гаилә учагы янында яшәргә тиеш. Безнең районыбызда моны беләләр, аңлыйлар. Татарстанда бары безнең Апас районында гына Үзәк мәйданда Ана һәйкәле бар. Ул барлык балаларга хәерле көн, хәерле юл, уңышлы эш көннәре теләп хәер – фатихасын биреп тора сыман. Күзләре ерак төбәлгән, гүя киләчәкне белгели. Ялгыз аналар иң акталь проблемаларның берсе.*
- ***Әниләр ялгыз булырга тиеш түгел.***

# Өй эше:

- 1. Әсәрнең 2 нче бүлеген укырга,
- 2. Ана һәйкәле салыну тарихын белүче ата – аналар юкмы икән, гаиләдә сөйләшегез.